Сарансктагы юридик факультет студенты телефон мошенникларына эшләгән очен суд карарын тынлаган.
Югары уку йортларынын бер-сенен юридик факультеты 2 курс студенткасынын жинаятьчел гамәлләрен узган елнын козендә РМ буенча Эчке эшләр министрлыгынын Жинаятьчеләрне эзләv идарәсе хезмәткәрләре, Саранск буенча Эчке эшләр министрлыгынын хезмәттәшләре белән берлектә тапты.       Тикшерv барышында ачыкланганча, 19 яшьлек кыз 76 һәм 79 яшьлек ике олкән гражданнан 420 мен сум алган. Ул инкассатор ролен vтәгән - алданган олкән яшьтәге кешеләрдән мошенниклык операцияләрен оештыручылар кvрсәтмәсе буенча кулларыннан акчаларын алган. РМ буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълvматы буенча, картларны телефон аферистлары аларнын туганнары катнашында ялган юл-транспорт һәлакәтләре турында билгеле схема буенча алдаганнар. Зыян кvрvчеләргә, имеш, операциягә ашыгыч рәвештә акча кирәк булган. Олкән яшьтәге кешеләрдән акчаны студент кыз шәхсән vзе такси хезмәте ярдәмендә жыйган. Урланган акчаларнын топ олешен кыз банкомат аша криминаль кураторларга кvчергән, ә vзенә хезмәт очен суммаларнын 5% калдырган. Мондый “подработка”ны ул vзе очен интернетта тапкан.
Шунысы игътибарга лаек: студент кыз vзенен уку йорты янында ук тоткарланган. Саранск шәһәрендә яшәvче хатын-кызга карата РФ Жинаять кодексынын 159 маддәсе буенча «мошенниклык» буенча жинаять эше кузгатканнар. Ул vз гаебен тулысынча таныган. Суд карары буенча ана 400 сәгать мәжбvри эш рәвешендә жәза билгеләнгән.